**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур., 29 нчы йорт. Тел.3-44-56

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29,
Тел. 3-44-56

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«20» ноябрь 2024 ел № 5

**Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегенең Иске Кормаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 18 ноябрендә Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегенең Иске Кормаш авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Төп мәсьәлә: "1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы ирекле хезмәткәрләрдән һәм Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлегенең Иске Кормаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, җыелган акчаларны җирлек буенча әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы? :

1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Кормаш торак пунктында су белән тәэмин итүне карап тоту);

2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Иске Кормаш торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм ремонтлау);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Кормаш торак пунктында җирлек чигенә стелла кую һәм аңа табличка ясау)

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Кормаш торак пунктындагы урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау ).

«РИЗА» 181
«КАРШЫ» -
«Тыелып калды»-

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 253 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 181 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен 181 граждан тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
«Тыелып калдылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлегенең Иске Кормаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны танырга: «1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы ирекле хезмәткәрләрдән һәм Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлегенең Иске Кормаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, җыелган акчаларны җирлек буенча әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы?»

1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Кормаш торак пунктында су белән тәэмин итүне карап тоту);

2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Иске Кормаш торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм ремонтлау);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Кормаш торак пунктында җирлек чигенә стелла кую һәм аңа табличка ясау)

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Кормаш торак пунктындагы урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау ).

3. Әлеге карарны Иске Кормаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aktanysh.tatar.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Д.Р. Вәлиева